МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.03.2023 Казан шәһәре 53

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыру, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс коралларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 24 июнендәге 300 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актны «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указына туры китерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыру, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс коралларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 24 июнендәге 300 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә:

Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга;

әлеге боерыкны өч көн эчендә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәргә;

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә ул расланган көннән алып өч көн эчендә тапшырырга, ә аннан соң, аңа үзгәрешләр кертелгәндә, үзгәрешләр кертелгәннән соң бер атна эчендә төгәлләнгән исемлекләрне тапшырырга.»;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыру, нал белән акча һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс коралларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының 2015
елның 24 июнендәге 300 номерлы
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
_______ № __________ боерыгы
редакциясендә)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыру, нал белән акча һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс коралларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары;
2. Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары – Эшкуарлыкны үстерү һәм конкуренция департаменты директоры;
3. Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары;
4. Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары – Социаль-икътисадый мониторинг департаменты башлыгы.